**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ ШЕШМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

ул.Комарова, д.14, с.Шешминская Крепость,
423104

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ШЕШМИНКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ**

Комаров урамы, 14 йорты, Шешминка Крепосте
авылы, 423104

тел./факс(84396) 2-36-54 email: Shesh.Cmn2@tatar.ru

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
Шешминка авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

31 октябрь 2019 ел № 149

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Шешминка крепосте авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Шешминка авыл җирлеге Уставының 22 статьясына туры китереп, 2019 елның 30 октябрендә кабул ителгән инициатив төркемнең язылу кәгазен карап, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлеге Советы ***КАРАР ИТТЕ:***

1. 2019 елның 8 ноябрендә 13 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Шешминка крепосте авылында гражданнарның үзара салым турындагы мәсьәләләрне ***хәл итү буенча гражданнар җыенының беренче этабын*** билгеләргә.

2. 2019 елның 8 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым мәсьәләләрен ***хәл итү буенча гражданнар җыенының икенче этабын*** билгеләргә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләләрне расларга:

3.1 Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлегендә гражданнар җыенының 2019 елның 20 сентябрендәге 141 номерлы үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Шешминка авыл җирлеге территориясендә җирле референдум оештыру һәм билгеләү мәсьәләсе буенча элек кабул ителгән карарын гамәлдән чыгарырга килешәсезме».

3.2. «Килешәсезме 2020 елда Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлеге территориясендә көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан,

Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүче гражданнардан, 1 төркем инвалидлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен:
- зиратларны төзекләндерү, реконструкцияләү, карап тоту (Андреевка торак пунктында киртәне урнаштыру, ремонтлау, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу)
- Шешминка крепосте торак пунктында суүткәргеч челтәрләренең проект һәм тикшеренү эшләре (инженерлык эзләнүләре, проект эшләре, проект экспертизасы), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу);
- Шешминка крепосте, Андреевка, Павловка, Нагай торак пунктларында урам утларын ремонтлау, карап тоту һәм хезмәт күрсәтү, кулланылган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- Шешминка крепосте һәм Андреевка торак пунктларында юл челтәрен кышкы чорда карап тоту һәм җәйге чорда чабу, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына һәм рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.
5. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Шешминка авыл җирлеге
Башлыгы, Совет рәисе: М.Д.Шәйхетдинов